1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле тәртиптә әлеге Указ нигезендә расланган Административ регламентка законнарда билгеләнгән очракларда үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне вакытында бирүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 ноябрендәге ПУ-901 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 23 октябрь
№ 722

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «23» октябрендәге
722 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартларын, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үздыру тәртибенә таләпләр, әлеге Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту рәвешләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының (алга таба шулай ук – Министрлык), аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе билгеләнә.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүче) түбәндәгеләр:

1) медицина эшчәнлеген башкарырга нияте булган яисә башкара торган медицина оешмалары һәм башка оешмалар (алга таба – тиешенчә лицензия алырга теләүче, лицензиат) яки аларның дәүләт хезмәте күрсәтүгә сорату

(алга таба – гариза) белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән вәкаләтле вәкилләре (алга таба шулай ук – гариза бирүченең вәкиле);

2) медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия турында мәгълүмат һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында башка мәгълүмат алу өчен мөрәҗәгать иткән физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар яисә аларның вәкаләтле вәкилләре.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (хезмәт күрсәтүче орган уздырган анкета сораштыруы нәтиҗәсендә ачыкланган гариза бирүче күрсәткән билгеләргә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) аны төрләргә бүлү күздә тотылмый.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчә – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү идарәсе медицина эшчәнлеген башкаруга лицензияләр бирү бүлеге (алга таба – лицензияләр бирү бүлеге).

Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

1) медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар – (алга таба – лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар);

2) медицина эшчәнлеген башкаруга лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында карар (алга таба тиешенчә – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында карар, лицензияләр реестры);

3) лицензиатның гаризасы буенча медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиянең гамәлен туктату (алга таба тиешенчә – лицензиянең гамәлен туктату, лицензия);

4) лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү (алга таба шулай ук – хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү).

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе Министрлык карары белән рәсмиләштерелә. Министрлыкның карары билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе «Россия сәламәтлек саклау күзәтчелеге (Лицензия бирүче орган)» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырыла.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә лицензияләр реестрыннан өземтә (алга таба – лицензияләр реестрыннан өземтә) рәвешендә электрон рәвештә юллана.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты:

1) лицензия алуга гариза (алга таба – лицензия алуга гариза) һәм аңа теркәп бирелә торган, әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 1 пунктчасында каралган документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән 15 эш көне;

2) түбәндәге очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза (алга таба – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза) һәм аңа теркәп бирелә торган, әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 2 пунктчасында каралган документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән биш эш көне (маршрут кәгазе буенча):

юридик затны үзгәртеп кору яисә кушылу рәвешендә яңадан оештыру;

юридик затның атамасы үзгәрү;

юридик зат урнашкан урынның адресы үзгәрү;

шәхси эшкуарның тору урыны үзгәрү;

шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта) үзгәрү;

шәхси эшкуарның шәхесен таныклый торган документның реквизитлары үзгәрү;

медицина эшчәнлеген башкару урынының адресы үзгәрү;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү әлеге норматив хокукый акт нигезендә билгеләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый акт нигезендә лицензия бирелә торган эшчәнлек төренең, медицина эшчәнлеге составында башкарыла торган эшләр, хезмәтләр исемлегенең атамасы үзгәрү;

бер яисә берничә адрес буенча күрсәтелә торган лицензиядә каралган медицина эшчәнлегенең туктатылуы;

лицензиатның лицензиядә каралган медицина эшчәнлеген тәшкил итүче эшләр, хезмәтләр исемлегенә эшләр, хезмәтләр күрсәтүне туктату өлешендә үзгәреш кертү нияте;

3) түбәндәге очракларда әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 3 пунктчасында каралган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза (алга таба – медицина эшчәнлеген башкаруга

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза) һәм аңа теркәп бирелә торган документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән 10 эш көне:

лицензиатның лицензиядә күрсәтелмәгән адрес буенча медицина эшчәнлеге башкару нияте;

лицензиатның лицензиядә күрсәтелмәгән медицина эшчәнлеген тәшкил итүче эшләр, хезмәт күрсәтүләр башкару нияте;

4) лицензиянең гамәлен туктату турында гариза кабул ителгән көннән өч эш көне;

5) лицензияләр реестрыннан белешмәләр алу турында гариза кабул ителгән көннән өч эш көне;

6) хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү – мөрәҗәгатьне теркәгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 8 кисәге һәм 18 статьясы $12^3$ кисәгендә каралган очракларда 15 эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен юллау түбәндәге срокларда башкарыла:

лицензия бирү турында, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә юллау – лицензия бирү турында, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында язып куелган көннән бер эш көне дәвамында;

лицензия бирүдән баш тарту турында, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту, лицензиянең гамәлен туктату, шулай ук лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында хәбәрнамә юллау – тиешле карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

«Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Төбәк порталы), Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольне тормышка ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм аларның вәкаләтле вазыйфаи затлары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вәкаләтле вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

2.6.1. Гариза бирүче тарафыннан бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) лицензия алу өчен:

а) Бердәм порталда яисә Төбәк порталында тутырылган лицензия алуга гариза;

б) гаризада күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләрне) өчен кирәкле, гариза бирүче милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган биналар, корылмалар һәм (яисә) алардагы бүлмәләргә Күчемсез милеккә һәм алар белән эш итүгә хокуклар бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән хокукын раслаучы документларның күчермәләре (әлеге хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән очракта – гариза бирүченең әлеге биналар, корылмалар һәм алардагы бүлмәләргә хокукы булуын раслаучы документларның реквизитлары турында мәгълүмат);

в) гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле медицина эшләнмәләренә (җиһазларга, аппаратларга, приборларга, инструментларга) милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булуын һәм алардан файдалану хокукын раслаучы документларның күчермәләре;

г) гариза бирүче белән хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләрнең медицина һәм фармация хезмәткәрләренә куелган квалификация таләпләре нигезендә каралган белеме һәм белгечнең аккредитация узуы яисә лицензия алырга теләүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле белгеч сертификаты булуын раслаган документлар күчермәләре;

д) гариза бирүче белән хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләрнең медицина эшләнмәләренә (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментларга) техник хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең тиешле һөнәри белеме һәм (яки) квалификациясе булуын раслаучы документларның күчермәләре яисә тиешле эшчәнлек алып барырга лицензиясе булган оешма белән шартнамә күчермәсе;

е) теркәп бирелә торган документларның исемлеге.

Лицензия алырга теләүче сәламәтлек саклау өлкәсе бердәм дәүләт мәгълүмат системасының медицина оешмалары федераль реестрына һәм медицина хезмәткәрләре федераль регистрына тиешле мәгълүмат тапшырган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасы «в» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документларның күчермәләрен бирү таләп ителми;

2) әлеге Административ регламентның 2.4 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен:

а) Бердәм порталда яисә Төбәк порталында тутырылган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза;

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (лицензиат – юридик затлар өчен) яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына (лицензиат – шәхси эшкуарлар өчен) кертү фактын раслаучы документ белешмәләре;

в) теркәп бирелә торган документлар исемлеге;

3) әлеге Административ регламентның 2.4 пункты 3 пунктчасында күрсәтелгән очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен:

а) Бердәм порталда яисә Төбәк порталында тутырылган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза;

б) әлеге пунктның 1 пунктчасы «б» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән документларның күчермәләре;

в) теркәп бирелә торган документлар исемлеге.

Лицензиат сәламәтлек саклау өлкәсе бердәм дәүләт мәгълүмат системасының медицина оешмалары федераль реестрына һәм медицина хезмәткәрләре федераль регистрына тиешле мәгълүмат тапшырган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасы «в» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документларның күчермәләрен бирү таләп ителми;

4) лицензиянең гамәлен туктату өчен – Бердәм порталда яисә Төбәк порталында тутырылган лицензиянең гамәлен туктату турында гариза;

5) тәгаен лицензия турында мәгълүмат алу өчен – Бердәм порталда яисә Төбәк порталында тутырылган лицензияләр реестрыннан белешмәләр алу турында гариза.

2.6.2. Лицензия алырга теләүче яисә лицензиат Министрлыкка документларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша электрон документ рәвешендә тапшыра.

Гариза бирүче гаризаны электрон рәвештә биргән очракта, гаризага һәм аңа электрон рәвештә теркәп бирелә торган документларга (белешмәләргә) әлеге Административ регламентның 2.6.3 пункты нигезендә электрон имзасын куя.

2.6.3. Гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) электрон рәвештә биргәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә файдалану мөмкин булган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы боерыгы нигезендә гариза бирүченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы кулланыла.

Гади электрон имзаны лицензия бирүче органга лицензияләр реестрыннан белешмәләр яисә лицензияләү турында башка белешмәләр алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә файдалану мөмкин булган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы боерыгында билгеләнгән очракларда файдаланырга мөмкин.

Гариза бирүче гади электрон имзасын яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә файдалана.

2.6.4. Министрлык дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында түбәндәгеләргә мәгълүмат бирү турында ведомствоара соратулар юллый:

1) Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

а) гариза бирүче турында язманы юридик затлар өчен – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яисә шәхси эшкуарлар өчен – Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы мәгълүмат бирү турында;

б) гариза бирүче – юридик затны, шәхси эшкуарны Россия Федерациясе территориясендә урнашкан урыны буенча салым органында исәпкә кую фактын раслаучы мәгълүмат бирү турында;

2) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – гариза бирүченең милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган, гаризада күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле, аларга хокукы Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрында теркәлгән биналары, корылмалары һәм (яисә) алардагы бүлмәләре булуы фактын раслаучы мәгълүмат бирү турында;

3) Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә – гариза бирүченең лицензия алырга теләүчегә яисә лицензиатка гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле биналарның, корылмаларның һәм (яисә) алардагы бүлмәләрнең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсен алу фактын раслаучы мәгълүмат бирү турында;

4) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы түләве фактын раслаучы мәгълүмат бирү турында.

Гариза бирүчеләр әлеге пунктта күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматларны үз теләге буенча бирергә хокуклы.

Әлеге документлар, мөмкинлек булганда, электрон формада юлланырга һәм әлеге Административ регламентның 2.6.3 пунктында күрсәтелгән документларны бирү өчен әлеге Административ регламентта билгеләнгән тәртиптә юлланырга мөмкин.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

2.8. Лицензия бирү һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне лицензия бирү яисә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә туктатып тору өчен нигезләр түбәндәгеләр:

1) лицензия алуга гаризаның әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 1 пунктчасы нигезендә тутырылмавы;

2) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүгә гаризаның әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 2 һәм 3 пунктчасы нигезендә тутырылмавы;

3) әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 1–3 пунктчасы нигезендә каралган документларның тулы күләмдә тапшырылмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты түбәндәге очракларда гариза бирүче тарафыннан Министрлыкның хәбәрнамә алынган вакыттан 15 эш көне дәвамында документлардагы ялгышларны төзәтү һәм (яисә) тапшырылмаган документларны бирү турында хәбәрнамәсен алган көннән 15 эш көне тәшкил итә:

1) лицензия алуга гаризаның әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 1 пунктчасы нигезендә тутырылмавы һәм документларның тулы күләмдә тапшырылмавы;

2) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүгә гаризаның әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 2 һәм 3 пунктчасы нигезендә тутырылмавы һәм документларның тулы күләмдә тапшырылмавы.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә баш тарту өчен нигезләр юк.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләүнең күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт пошлинасы күләме турында мәгълүмат Бердәм порталда, Төбәк порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Дәүләт хезмәте күрсәткән (лицензия биргән, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән) өчен Россия Федерациясе Салым кодексының $333^{33}$ статьясы 1 пункты 92 пунктчасында билгеләнгән күләмдә дәүләт пошлинасы түләнә.

Лицензияләр реестрыннан өземтә, лицензия бирүче органның кабул ителгән карары акты күчермәсе рәвешендә, лицензияләр реестрында лицензияләр турында белешмәләр яисә тәгаен лицензиатны билгеләп булмаган очракта соратыла торган белешмәләрнең булмавы турында бирелә торган белешмә рәвешендә лицензияләр реестрыннан бушлай бирелә.

2.10. Гариза биргән вакытта чират көтү вакыты билгеләнми, чөнки гариза Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша бирелә.

2.11. Гаризаны теркәү срогы.

2.11.1. Гаризаны теркәү срогы – гариза Министрлыкта кергән көннән бер эш көне.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә бирелгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр куелмый, чөнки дәүләт хезмәте Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша күрсәтелә.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары, Министрлыкның, аның вәкаләтле вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүматның ачык кулланышта булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү стандартларының үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең, башка затларның Министрлыкның, аның вәкаләтле вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) нигезле рәвештә шикаять бирелмәве;

Министрлыкның, аның вәкаләтле вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе;

гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны электрон имза куелган электрон документ рәвешендә Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтенең электрон рәвештә күрсәтелүе.

2.13.3. Гариза бирүченең (аның вәкиленең) Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлеге.

Гариза Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша бирелгәндә гариза бирүче Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итми.

Гариза бирүчеләргә Бердәм порталда, Төбәк порталында һәм Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсен һәм аның сыйфатын бәяләү мөмкинлеге бирелә.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталдан, Төбәк порталыннан алырга мөмкин.

2.13.5. Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтүнең үзенчәлекләре һәм дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтүнең үзенчәлекләре исәпкә алынган;

дәүләт хезмәте турында мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында.

2.14.1. Күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Россия сәламәтлек саклау күзәтчелеге (Лицензия бирүче орган)» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланыла.

2.14.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм Төбәк порталында урнаштырыла.

## III. Административ процедураларның составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә түбәндәге административ процедуралар керә:

лицензия бирү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында (үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

лицензиат яисә аның хокукый дәвамчысы гаризасы буенча лицензиянең гамәлен туктату;

лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү.

### Лицензия бирү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензияне бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.2. «Лицензия бирү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензияне бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү» административ процедурасы Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша электрон документлар рәвешендә Министрлыкка лицензия бирү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) алыну белән бәйле рәвештә башкарыла.

3.2.1. Лицензия бирү турындагы гариза һәм документлар (мәгълүматлар) Министрлык тарафыннан, кабул итү датасын күрсәтеп, исемлек нигезендә кабул ителә, лицензия алырга теләүчегә, аның Бердәм порталдагы шәхси кабинетыннан файдаланып, гаризаның һәм аңа теркәлгән документларның (мәгълүматларның) кабул ителү датасы расланган хәбәрнамә юллана.

3.3. Алынган документларның исәбен алып баруга контрольлек итүне Министрлыкның медицина эшчәнлегенә лицензияләр бирү бүлеге башлыгы үти.

3.4. Лицензияләр бирү бүлеге башлыгы лицензия бирү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) Министрлыкта теркәлгән көннән бер эш көне эчендә лицензияләр бирү бүлеге хезмәткәрләре арасыннан лицензия

алырга теләүче тарафыннан лицензия алу өчен бирелгән документларны карауга җаваплы башкаручыны (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели.

3.5. Гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.10 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) карау, лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карарны кабул итү әлеге Административ регламентның 2.4 пунктының 1 пунктчасында каралган вакыт эчендә башкарыла.

3.6. Министрлыкта әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасы таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән лицензия бирү турында гариза һәм документлар (мәгълүматлар) алынганда, җаваплы башкаручы аларны кабул иткән көннән өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә ачыкланган җитешсезлекләрне 15 көндә бетерү һәм (яки) җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамә тапшыра яисә мондый хәбәрнамәне тапшыру турында хәбәр белән почта аша заказлы хат итеп яисә лицензия алырга теләүче теләге буенча квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын раслауны һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын тәэмин итә торган ысул белән юллый.

3.7. Лицензия алырга теләүче лицензия алырга теләүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә алынган көннән 15 көн эчендә лицензия бирү турында тиешенчә тутырылган гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) тулы күләмдә тапшырмаган очракта, җаваплы башкаручы өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кайтарып бирү турында хәбәрнамәне, кайтарып бирүнең нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылу турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яисә лицензия алырга теләүченең теләге белән квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә юллый.

3.8. Җаваплы башкаручы Министрлыкта тиешенчә тутырылган гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) алынган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, бирелгән белешмәләрнең, шул исәптән лицензия алырга теләүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләүне Министрлыкта ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән түбәндәгеләрдән алынган:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында (юридик затлар өчен), Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында (шәхси эшкуарлар өчен) лицензия алырга теләүче турындагы мәгълүматларны, шулай ук лицензия алырга теләүче юридик затның, шәхси эшкуарның Россия Федерациясе территориясендә урнашу җире буенча салым органында исәпкә басуы турында мәгълүматларның;

Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – лицензия алырга теләүченең милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган, медицина эшчәнлеген тәшкил иткән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле һәм билгеләнгән таләпләргә туры килә торган биналары, корылмалары һәм (яисә) алардагы бүлмәләре булуын раслый торган мәгълүматларның;

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсеннән – лицензия алырга теләүченең гаризада күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле биналары, корылмалары һәм (яисә) бүлмәләренең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булу турында мәгълүматларның;

Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматларның тулы күләмдә бирелгән булуын һәм дөреслеккә туры килүен тикшерүне уздыра.

3.9. Лицензия алырга теләүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләү Министрлык боерыгы белән расланган бәяләү кәгазе нигезендә башкарыла.

Бәяләү йомгаклары буенча лицензия алырга теләүченең лицензия бирелергә тиешле эшчәнлек төрен тәшкил иткән кайбер эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән лицензия алырга теләүче башкарырга, лицензия алына торган эшчәнлек төренең бер яисә берничә урынында хезмәт күрсәтергә ниятләгән кайбер эшләр, хезмәтләр) кагылышлы лицензия алу таләпләренә туры килмәве ачыкланганда, әлеге лицензия алырга теләүчегә лицензия аның теләге буенча әлеге бәяләмә барышында аларга карата лицензия алырга теләүченең лицензия алу таләпләренә туры килүе расланган лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрен тәшкил иткән эш һәм хезмәтләр төрләренә (шул исәптән лицензия алырга теләүче башкарырга, лицензия алына торган эшчәнлек төренең бер яисә берничә урынында хезмәт күрсәтергә ниятләгән эшләр, хезмәтләр) бирелә.

3.10. Лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны (белешмәләрне) тулы күләмдә биргән яисә ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтергә һәм җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергән очракта, җаваплы башкаручы гариза һәм документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ юллау аша да, аларның Министрлык тарафыннан карауга кабул ителүе турында хәбәр итә, шулай ук юридик затның, шәхси эшкуарның лицензияләү таләпләренә туры килүен ачыклау өчен планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында боерык проектын әзерли.

3.10.1. Күчмә тикшерү уздыру турында лицензия алырга теләүчегә Министрлык тарафыннан аны уздыруга өч эш көне кала мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ юллау аша хәбәр ителә.

3.10.2. Дистанцион элемтә чараларын кулланып уздырылган күчмә тикшерү аудио-яисә видеоэлемтә ярдәмендә башкарыла. Әгәр лицензия алырга теләүченең лицензияләү таләпләренә туры килүен күчмә тикшерү барышында фотога төшерү һәм (яки) видеога яздыру барса, тикшерү актында шул турыда билге куела, һәм аңа җитәкче, башка берәр вазыйфаи зат яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиле тарафыннан кул кую таләп ителми. Бу очракта фотога төшерү һәм (яки) видеога яздыру материаллары тикшерү актына теркәлә. Лицензия алырга теләүченең лицензияләү таләпләренә туры килүен күчмә тикшерү йомгаклары тикшерү акты рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.10.3. Лицензия алырга теләүче лицензияләнергә тиешле эш төрен башкарганда файдаланырга ниятләгән производство объектлары, техник чаралар, җиһазлар, башка объектларның хәл торышы һәм лицензияләнергә тиешле эш төрен башкару өчен хезмәткәрләрнең булуы планнан тыш күчмә тикшерү предметы булып тора.

3.10.4. Күчмә тикшерү уздырганда Министрлык мондый тикшерү уздыруга тикшерүе йомгакларында кызыксынмаган, Россия Федерациясенең аккредитация турында законнары нигезендә илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләнгән экспертлар һәм эксперт оешмаларын, шулай ук эксперт яки күрсәтелгән оешмалар эшчәнлек алып бара торган, Министрлык карамагындагы оешмаларны (алга таба – экспертлар) җәлеп итәргә мөмкин.

3.10.4.1. Экспертларны җәлеп итү Министрлыкның вәкаләтле заты кул куйган карар нигезендә лицензия алырга теләүчеләр өчен түләүсез башкарыла.

3.10.4.2. Экспертларның фикерләре экспертлар һәм вәкаләтле вазыйфаи затлар кул куйган, тикшерү актына теркәлә торган белешмәдә (экспертлар фикерендә) бәян ителә.

3.10.5. Лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланганда, тикшерү актында аның нинди таләпләргә туры килмәве һәм мондый лицензияләү таләбе дәүләт хезмәтен күрсәтүне җайга салучы нинди норматив хокукый акт нигезендә кертелүе күрсәтелә.

3.11. Лицензия алырга теләүчегә карата планнан тыш күчмә тикшерү тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә җаваплы башкаручы бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм планнан тыш күчмә тикшерү йомгаклары буенча түбәндәгеләр турында боерык проектын әзерли:

1) лицензия бирү турында;

2) түбәндәге очракларда лицензия бирүдән баш тарту турында:

а) лицензия алырга теләүче биргән лицензия бирү турында гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат булганда;

б) тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланганда.

Лицензия алырга теләүче Министрлык тарафыннан лицензия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгәнче гаризасын кире алырга хокуклы.

3.12. Министрлыкның лицензия бирү турында боерыгы Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.13. Министрлыкның лицензия бирү турында боерыгында түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) лицензия бирә торган органның атамасы;

2) юридик затның тулы һәм кыскартылган (булган очракта) атамасы, шул исәптән хосусый атамасы һәм оештыру-хокукый формасы, урнашкан урыны адресы, медицина эшчәнлеген башкару урыны адресы, юридик зат төзү турында язманың дәүләт теркәвенә алыну номеры;

3) шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документлар атамасы һәм реквизитлары, аның яшәгән урыны адресы, лицензия бирелә торган эш төрен башкару урыны адресы, шәхси эшкуарның дәүләт теркәвенә алынуы турында язманың дәүләт теркәвенә алу номеры;

4) салым түләүченең идентификация номеры;

5) лицензияләнә торган эшчәнлек төре – медицина эшчәнлеге;

6) Министрлыкның лицензия бирү турында боерыгының номеры һәм датасы.

3.14. Министрлык тарафыннан лицензия бирү турында карар кабул ителсә, Министрлыкның медицина эшчәнлеге башкаруга лицензия бирү турындагы боерыгы теркәлгән көндә лицензияләр реестрына язып куела.

3.15. Лицензия бирү турындагы боерык теркәлгән көндә лицензияләр реестрына язып куелган көннән соң бер эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә лицензия бирелү турында көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендәге хәбәрнамәне юллый. Хәбәрнамә лицензия алырга теләүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетын файдаланып юллана.

3.16. Лицензия бирү турындагы гаризада лицензия алырга теләүче лицензияләр реестрыннан электрон документ рәвешендә өземтә алырга кирәклеген күрсәткән булса, җаваплы башкаручы лицензия бирү турындагы хәбәрнамәне юллау белән бергә лицензия алырга теләүчегә лицензияләр реестрыннан квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә өземтә җибәрә.

3.17. Лицензия бирелү турында хәбәрнамә һәм лицензияләр реестрыннан өземтә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.18. Лицензия бирүдән баш тарту турында боерыкка кул куелган көннән өч эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә лицензия бирүдән баш тарту турында аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәлгән заказлы хат рәвешендә яисә лицензия алырга теләүченең теләге буенча квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә хәбәрнамә, мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән юллый.

Лицензия бирүдән баш тарту турында хәбәрнамәдә баш тартуның нигезле сәбәпләре һәм лицензия бирүдән баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм башка документларның нигезләмәләре күрсәтелә. Баш тартуның сәбәбе лицензия алырга теләүченең тикшерү барышында ачыкланган лицензия бирү таләпләренә туры килмәве булса, лицензия алырга теләүченең таләпләргә туры килүен тикшерү акты реквизитлары күрсәтелә.

3.19. Лицензия бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.20. Министрлык тарафыннан лицензия бирү турында яисә лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен бирелгән вакыт Министрлыкка лицензия бирү турында тиешенчә тутырылган гариза һәм аңа теркәлгән тулы күләмдә документлар (мәгълүматлар) алынган көннән башлап исәпләнә.

3.21. Административ процедура буенча карар кабул иткәндә лицензия бирмәү өчен нигезләр булуга яисә булмауга таянып эш ителә.

3.22. Административ процедураның нәтиҗәсе – лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

3.23. Лицензия бирү турында яисә лицензия бирүдән баш тарту турында Министрлыкның боерыгын чыгару һәм лицензия бирү турында лицензияләр реестрына язып кую административ процедура нәтиҗәсен теркәү ысулы булып тора.

### Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (кертүдән баш тарту) турында карар кабул итү

3.24. «Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) карау һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (кертүдән баш тарту) турында карар кабул итү» административ процедурасы Министрлыкка Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 һәм 3 пунктчаларында каралган документлар (мәгълүматлар) килүе белән бәйле рәвештә башкарыла.

3.25. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм документлар (мәгълүматлар) Министрлык тарафыннан, кабул итү датасын күрсәтеп, исемлек нигезендә кабул ителә. Лицензия алырга теләүчегә, аның Бердәм порталдагы шәхси кабинетыннан файдаланып, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаның һәм аңа теркәлгән документларның (мәгълүматларның) кабул ителү датасы расланган хәбәрнамә юллана.

3.26. Алынган документларның исәбен алып баруга контрольлек итүне лицензияләр бирү бүлеге башлыгы үти.

3.27. Лицензияләр бирү бүлеге башлыгы лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) Министрлыкта теркәлгән көннән бер эш көне эчендә лицензияләр бирү бүлеге хезмәткәрләре арасыннан җаваплы башкаручыны билгели.

3.28. Гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) карау, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында карарны кабул итү әлеге Административ регламентның 2.4 пунктының 2 пунктчасында каралган вакыт эчендә башкарыла.

3.29. Министрлыкта әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасы таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм документлар (мәгълүматлар) алынганда, җаваплы башкаручы аларны кабул иткән көннән өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә ачыкланган җитешсезлекләрне 15 көндә бетерү һәм (яки) җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамәне мондый хәбәрнамәне тапшыру турында хәбәр белән почта аша заказлы хат итеп яисә лицензия алырга теләүче теләге буенча квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын раслауны һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын тәэмин итә торган ысул белән юллый.

3.30. Лицензия алырга теләүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 3.29 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә алынган көннән 15 көн эчендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) лицензия алырга теләүче тулы күләмдә тапшырмаган очракта, җаваплы башкаручы өч эш көне эчендә лицензиатка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кайтарып бирү турында хәбәрнамәне, кайтарып бирүнең нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылу турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яисә лицензия алырга теләүченең теләге белән квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын раслауны һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын тәэмин итә торган ысул белән юллый.

3.31. Җаваплы башкаручы Министрлыкта лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) алынган яисә ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтергә һәм җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне 15 көн эчендә бетергән очракта, җаваплы башкаручы лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм документлар (мәгълүматлар) кабул ителгән көннән өч эш көне дәвамында лицензия алырга теләүчегә мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ юллау аша да, аларның Министрлык тарафыннан карауга кабул ителүе турында хәбәр итә.

Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында яисә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен бирелгән вакыт Министрлыкка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гариза һәм аңа теркәлгән тулы күләмдә документлар (мәгълүматлар) алынган көннән башлап исәпләнә.

3.32. Министрлыкка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гариза һәм аңа теркәлгән тулы күләмдә документлар (мәгълүматлар) алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килүенә тикшерү, шул исәптән бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген, лицензиат турында лицензия эшендә булган мәгълүматларны да исәпкә алып, түбәндәгеләрне билгеләү максатында тикшерү уздыра:

1) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен нигез булуны;

2) гаризада һәм документларда, шул исәптән Министрлыкта ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән түбәндәгеләрдән алынган белешмәләрнең:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында (юридик затлар өчен), Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында (шәхси эшкуарлар өчен) лицензия алырга теләүче турындагы мәгълүматларны, шулай ук медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия алырга теләүче юридик затның, шәхси эшкуарның Россия Федерациясе территориясендә урнашу җире буенча салым органында исәпкә басуы турында мәгълүматларның;

Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматлар.

3.33. Лицензия алырга теләүче тарафыннан бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә җаваплы башкаручы түбәндәгеләр турында боерык проектын әзерли:

1) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында;

2) лицензия алырга теләүче биргән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат булганда, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында.

Лицензия алырга теләүче Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгәнче лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризасын кире алырга хокуклы.

3.34. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыгы Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.35. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыгында түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) лицензия бирә торган органның атамасы;

2) юридик затның тулы һәм кыскартылган (булган очракта) атамасы, шул исәптән хосусый атамасы һәм оештыру-хокукый формасы, урнашкан урыны адресы, медицина эшчәнлеген башкару урыны адресы, юридик зат төзү турында язманың дәүләт теркәвенә алыну номеры;

3) шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документлар атамасы һәм реквизитлары, аның яшәгән урыны адресы, лицензия бирелә торган эш төрен башкару урыны адресы, шәхси эшкуарның дәүләт теркәвенә алынуы турында язманың дәүләт теркәвенә алу номеры;

4) салым түләүченең идентификация номеры;

5) лицензияләнә торган эшчәнлек төре – медицина эшчәнлеге;

6) Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыгының номеры һәм датасы.

3.36. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы боерыгы реквизитлары лицензияләр реестрына язып куела.

3.37. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында лицензияләр реестрына язып куелган көннән соң бер эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендәге хәбәрнамәне юллый. Хәбәрнамә лицензия алырга теләүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетын файдаланып юллана.

3.38. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризада лицензия алырга теләүче лицензияләр реестрыннан электрон документ рәвешендә өземтә алырга кирәклеген күрсәткән булса, җаваплы башкаручы лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелү турындагы хәбәрнамәне юллау белән бергә лицензия алырга теләүчегә лицензияләр реестрыннан квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә өземтә җибәрә.

3.39. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә һәм лицензияләр реестрыннан өземтә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.40. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыгына кул куелган көннән өч эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәлгән заказлы хат рәвешендә хәбәрнамә яисә лицензия алырга теләүченең теләге буенча квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән юллый. Баш тарту турында хәбәрнамәдә баш тартуның нигезле сәбәпләре һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм башка документларның нигезләмәләре күрсәтелә.

3.41. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хәбәрнамә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

3.42. Лицензияләр бирү бүлеге башлыгы Министрлыкта лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) теркәлгән көннән бер эш көне эчендә бүлек хезмәткәрләре арасыннан җаваплы башкаручыны билгели.

3.43. Гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) карау, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында (үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында) карарны кабул итү әлеге Административ регламентның 2.4 пунктының 3 пунктчасында каралган вакыт эчендә башкарыла.

3.44. Министрлыкта әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасы таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм документлар (мәгълүматлар) алынганда, җаваплы башкаручы аларны кабул иткән көннән өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә ачыкланган җитешсезлекләрне 15 көндә бетерү һәм (яки) җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамәне мондый хәбәрнамәне тапшыру турында хәбәр белән почта аша заказлы хат итеп яисә лицензия алырга теләүче теләге буенча квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын раслауны һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын тәэмин итә торган ысул белән юллый.

3.45. Лицензия алырга теләүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 3.43 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә алынган көннән 15 көн эчендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында каралган документларны (мәгълүматларны) лицензия алырга теләүче тулы күләмдә тапшырмаган очракта, җаваплы башкаручы өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә лицензияләр

реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кайтарып бирү турында хәбәрнамәне, кайтарып бирүнең нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылу турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яисә лицензия алырга теләүченең теләге белән квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә мондый хәбәрнамәнең тапшырылуын раслауны һәм лицензия алырга теләүченең аны алуын тәэмин итә торган ысул белән юллый.

3.46. Министрлыкка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә тутырылган гариза һәм Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында каралган документлар (мәгълүматлар) алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килүенә тикшерү, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән бирелгәннәрен дә кертеп, бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген, түбәндәгеләрне билгеләү максатында тикшерү уздыра:

1) әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында билгеләнгән документларның (документларның тулылыгы) булуы;

2) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен нигез булу.

3.47. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында җаваплы башкаручы түбәндәгеләрдән белешмәләр ала:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында (юридик затлар өчен), Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында (шәхси эшкуарлар өчен) лицензия алырга теләүче турындагы мәгълүматларны, шулай ук лицензия алырга теләүченең (юридик затның, шәхси эшкуарның) Россия Федерациясе территориясендә урнашу җире буенча салым органында исәпкә басуы турында мәгълүматлар;

Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – лицензия алырга теләүченең милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган, медицина эшчәнлеген тәшкил иткән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле һәм билгеләнгән таләпләргә туры килә торган биналары, корылмалары һәм (яисә) алардагы бүлмәләре булуын раслый торган мәгълүматлар;

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсеннән – лицензия алырга теләүченең гаризада күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле биналары, корылмалары һәм (яисә) бүлмәләренең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булу турында мәгълүматлар;

Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы мәгълүматлар.

3.48. Лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасында каралган документларны (белешмәләрне) тулы күләмдә биргән яисә ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтергә һәм җитешмәгән документларны бирү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне 15 эш көне эчендә бетергән очракта, җаваплы башкаручы гариза һәм документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүчегә мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ юллау аша да, аларның Министрлык тарафыннан карауга кабул ителүе турында хәбәр итә, шулай ук юридик затның, шәхси эшкуарның лицензияләү таләпләренә туры килүен ачыклау өчен планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында боерык проектын әзерли.

3.48.1. Күчмә тикшерү уздыру турында лицензия алырга теләүчегә Министрлык тарафыннан аны уздыруга өч эш көне кала мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ юллау аша хәбәр ителә.

3.48.2. Дистанцион элемтә чараларын кулланып уздырылган күчмә тикшерү аудио-яисә видеоэлемтә ярдәмендә башкарыла. Әгәр лицензия алырга теләүченең лицензияләү таләпләренә туры килүен күчмә тикшерү барышында фотога төшерү һәм (яки) видеога яздыру барса, тикшерү актында шул турыда билге куела һәм аңа җитәкче, башка берәр вазыйфаи зат яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиле тарафыннан кул кую таләп ителми. Бу очракта фотога төшерү һәм (яки) видеога яздыру материаллары тикшерү актына теркәлә. Лицензия алырга теләүченең лицензияләү таләпләренә туры килүен күчмә тикшерү йомгаклары тикшерү акты рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.48.3. Лицензиат тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкарганда куллану күздә тотылган җитештерү объектларының, техник чараларның, җиһазларның, башка объектларның торышы һәм лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару өчен кирәкле хезмәткәрләрнең булуы, әлеге объектларның һәм хезмәткәрләрнең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү максатларында, планнан тыш күчмә бәяләү уздыру предметы булып тора.

3.48.4. Лицензиатның лицензия таләпләренә туры килү-килмәвенә күчмә бәяләү уздырганда Министрлык әлеге тикшерү уздыруга Россия Федерациясенең илкүләм аккредитация системасында аккредитация турында законнары нигезендә аккредитация алган, бәяләү йомгакларына карата кызыксындыру белдермәгән экспертларны яисә эксперт оешмаларын (алга таба – экспертлар), шулай ук Министрлык карамагындагы эксперт яисә әлеге оешмалар эшчәнлек алып барган урында урнашкан оешмаларны җәлеп итәргә мөмкин.

Экспертларның фикерләре экспертлар һәм вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан кул куелган, бәя бирү турында актка теркәп бирелә торган белешмәдә (эксперт фикерендә) бәян ителә.

3.48.5. Лицензиатның лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланган очракта, бәя бирү актында лицензиатның нәкъ менә кайсы лицензия таләпләренә туры килмәве, дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган кайсы норматив хокукый акт нигезендә әлеге лицензия таләбе билгеләнгән икәнлеге күрсәтелә.

3.49. Планнан тыш күчмә бәяләү тәмамланганнан соң өч эш көне дәвамында җаваплы башкаручы лицензиат тарафыннан бирелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм планнан тыш күчмә бәяләү йомгакларын исәпкә алып, түбәндәгеләр турында боерык проектын әзерли:

1) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында;

2) түбәндәге очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында:

а) лицензиат тарафыннан бирелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат булганда;

б) бәяләү уздыру барышында лицензиатның лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланганда.

Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яисә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгәнче, лицензиат лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризасын кире алырга мөмкин.

3.50. Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелү турында язма лицензияләр реестрына Министрлык боерыгы теркәлгән көнне кертелә.

3.51. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыгында әлеге Административ регламентның 3.35 пунктында каралган мәгълүматлар булырга тиеш.

3.52. Министрлыкның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыгы реквизитлары лицензияләр реестрына кертелә.

3.53. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында язып куелган көннән соң бер эш көне дәвамында җаваплы башкаручы лицензиатка лицензиатның Бердәм порталдагы шәхси кабинеты аша лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә хәбәрнамә җибәрә.

3.54. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризада лицензиат лицензияләр реестрыннан өземтә алырга кирәклеген күрсәткән булса, җаваплы башкаручы лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамәне юллау белән бергә лицензиатка квалификацияле

көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрә.

3.55. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамәгә һәм лицензияләр реестрыннан өземтәгә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат кул куя.

3.56. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыкка кул куелган көннән өч эш көне дәвамында җаваплы башкаручы лицензиатка әлеге хәбәрнамәне лицензиатка китереп җиткерүне һәм лицензиатның аны алуын раслауны тәэмин итүче юл белән лицензиатның кайсын сайлавына карап, почта аша заказлы хат рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хәбәрнамә юллый. Баш тарту турында хәбәрнамәдә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тартуга нигез булган норматив хокукый актлар нигезләмәләренә һәм башка документларга сылтама биреп, баш тартуның нигезле сәбәпләре күрсәтелә.

3.57. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хәбәрнамәгә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат кул куя.

3.58. Административ процедура буенча карар кабул иткәндә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигезләр булуга яисә булмауга таянып эш итела.

3.59. Административ процедураның нәтиҗәсе – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (реестрга үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

3.60. Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яисә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык чыгару һәм лицензияләр реестрына тиешле язма кертү административ процедура нәтиҗәсен беркетү ысулы булып тора.

Лицензиатның яисә аның хокукый дәвамчысының гаризасы буенча лицензиянең гамәлен туктату

3.61. «Лицензиатның яисә аның хокукый дәвамчысының гаризасы буенча лицензиянең гамәлен туктату» административ процедурасы Министрлыкка лицензиаттан яисә аның хокукый дәвамчысыннан Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша электрон документ рәвешендә әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 4 пунктчасы нигезендә медицина эшчәнлеген туктату турында гариза керү белән бәйле рәвештә башкарыла.

3.62. Лицензияләр бирү бүлеге башлыгы Министрлыкка кергән әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 4 пунктчасында күрсәтелгән лицензиянең гамәлен туктату турында гариза рәсмиләштерелгән көннән бер эш көне дәвамында лицензияләр бирү бүлеге хезмәткәрләре арасыннан җаваплы башкаручыны билгели.

3.63. Җаваплы башкаручы Министрлыкка тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән лицензиянең гамәлен туктату турында гариза кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне башкара:

1) лицензияләү документлары тупланмасында лицензиат турында булган мәгълүматларны исәпкә алып, тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген бәяли;

2) лицензиянең гамәлен туктату турында боерык проектын рәсмиләштерә.

3.64. Министрлыкның лицензиянең гамәлен туктату турында карары медицина эшчәнлеген туктату турында боерык буларак рәсмиләштерелә.

3.65. Лицензиянең гамәле лицензияләр реестрына тиешенчә язып куелган көннән туктатыла (лицензиянең гамәлен туктату турында боерык теркәлгән көнне язып куела).

Җаваплы башкаручы лицензияләр реестрына лицензиянең гамәлен туктату турында мәгълүматны лицензиаттан медицина эшчәнлеген башкаруын туктату турында гариза кергән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча кертә.

3.66. Министрлыкның лицензиянең гамәлен туктату турында боерыгына Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи заты кул куя.

3.67. Лицензиянең гамәлен туктату турында боерыкның реквизитлары медицина эшчәнлеген башкаруга лицензияләр реестрына кертелә.

3.68. Лицензияләр реестрына медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиянең гамәлен туктату турында язып куелган көннән өч эш көне дәвамында Министрлык тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиянең гамәлен туктату турында хәбәрнамә җибәрелә.

3.69. Лицензиянең гамәлен туктату турында хәбәрнамәгә һәм лицензияләр реестрыннан белешмәләргә Министрлык исеменнән кул кую хокукы булган вәкаләтле вазыйфаи зат кул куя.

3.70. Лицензиянең гамәлен туктату белән бәйле документларны җаваплы башкаручы лицензияләү документлары тупланмасына өстәп куя.

3.71. Административ процедура буенча карар кабул иткәндә лицензиаттан медицина эшчәнлеген башкаруын туктату турында гариза алынуына таянып эш ителә.

3.72. Лицензиянең гамәлен туктату административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.73. Лицензиянең гамәлен туктату турында боерык чыгару һәм лицензияләр реестрына тиешенчә язып кую административ процедура нәтиҗәсен беркетү ысулы булып тора.

## Лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү

3.74. «Лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү» административ процедурасы Министрлыкка физик заттан, шул исәптән шәхси эшкуардан яисә юридик заттан әлеге Административ регламентның 2.6.1 пункты 5 пунктчасы нигезендә Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша электрон документ рәвешендә гариза алыну белән бәйле рәвештә башкарыла.

3.75. Җаваплы башкаручы Министрлыкка лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гариза алынган көннән өч эш көне дәвамында түбәндәгеләрне башкара:

1) лицензияләр реестрында лицензия турында мәгълүматларның булуын тикшерә;

2) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә лицензия турында мәгълүматларны һәм лицензия бирүче органның кабул ителгән карары турында боерыгының күчермәсен рәсмиләштерә һәм аларны гариза бирүчегә җибәрә (бирә);

3) лицензияләр реестрында лицензияләр турында мәгълүмат булмаган яисә лицензиатны билгеләү мөмкин булмаган очракта, гариза бирүчегә лицензияләр реестрында соратылган мәгълүматларның булмавы турында белешмә җибәрә (бирә).

3.76. Лицензия турында мәгълүмат көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә юллана.

3.77. Административ процедура буенча карар кабул иткәндә лицензияләр реестрында тәгаен лицензия турында мәгълүматларның булуына яки булмавына таянып эш ителә.

3.78. Гариза бирүчегә лицензияләр реестрыннан әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча мәгълүматларны яисә соратылган мәгълүматларның булмавы турында белешмәне бирү (җибәрү) административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.79. Лицензияләр реестрыннан өземтәне яисә соратылган мәгълүматларның булмавы турында белешмәне яисә лицензия бирүче органның кабул ителгән карар турында боерыгының күчермәсен рәсмиләштерү административ процедура нәтиҗәсен беркетү ысулы булып тора.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү

3.80. Гариза бирүче тарафыннан лицензияләр реестрында һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар ачыкланган очракта, гариза бирүче Министрлыкка әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә форма буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында гариза бирә.

3.81. Җаваплы башкаручы дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында гариза алынган көннән бер эш көне дәвамында гаризада күрсәтелгән мәгълүматны тикшерә.

3.82. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы Министрлыкта билгеләнгән эш башкару тәртибе нигезендә тиешле гаризаны теркәгән көннән өч эш көненнән артык булмаган вакыт эчендә әлеге хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтә.

3.83. Административ процедура буенча карар кабул иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарының һәм (яисә) ялгышларның булуына яки булмавына таянып эш ителә.

3.84. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яки) ялгышларны төзәтү яисә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарының һәм (яки) ялгышларның булмавы турында мәгълүмат булган хат юллау административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.85. Лицензияләр реестрындагы ялгышларны төзәтү һәм хәреф хаталары һәм (яки) ялгышлар төзәтелгәннән соң әзерләнгән документлар административ процедура нәтиҗәсен беркетү ысулы булып тора.

3.86. Әлеге административ процедураны (гамәлне) башкару вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына керми.

## IV. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлеше, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат яки министрның дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы беренче урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контроль Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән алып барыла.

Агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүдән, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, гариза бирүчеләрнең Министрлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләре кертелгән мөрәҗәгатьләрен карап

тикшерүдән, алар буенча карарлар кабул итүдән һәм җаваплар әзерләүдән тора.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү Министрлык актлары нигезендә башкарыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш була ала.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләре бозылуның элегрәк ачыкланган очракларын бетерүне тикшерү;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вәкаләтле вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) сәбәпле гражданнар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында шикаять белән мөрәҗәгать итүе.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольдә тоту нәтиҗәләре буенча гариза бирүче хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелүне гариза бирүчеләр тарафыннан контрольдә тоту әлеге Административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлыкның, аның вәкаләтле вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү юлы белән башкарыла.

## V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә башкарыла торган һәм әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләрен боза торган гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның, аның вәкаләтле вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм алар тарафыннан кабул ителгән (башкарыла торган) карарлар судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып тора.

Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) гаризаны теркәү срогы үтәлмәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы үтәлмәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тартуның нигезләре федераль законнарда яисә Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен каралмаган түләүне гариза бирүчедән таләп итү;

7) Министрлыкның, шулай ук аның вәкаләтле вазыйфаи затларының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә әлеге хатларны төзәтү өчен бирелгән срокларны үтәмәве;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын яисә тәртибен үтәмәү;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларда, әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы яисә дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.3. Шикаять язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша яисә электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Министрлыкның рәсми сайты (http://minzdrav.tatarstan.ru), Төбәк порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша юлланырга, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган Министрлыкның атамасы, аның җитәкчесенең һәм (яисә) Министрлык хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм (яисә) вазыйфасы;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), урнашкан урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының карарлары һәм гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) ризасызлыгына нигез булган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан үз дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять, ул тапшырылган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү срогы – теркәлгән көннән 15 эш көне дәвамында, ә Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә әлеге хатларны төзү өчен бирелгән срокларны үтәмәвенә шикаять бирелгән очракта – теркәлгән көннән биш эш көне дәвамында.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, әлеге Административ регламент нигезендә түләү каралмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында.

5.8. Әлеге Административ регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карарны кабул итү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм аның теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Административ регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны бетерү максатында Министрлык тарафыннан кичектермәстән башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат, шулай ук уңайсызлыклар китергән өчен гариза бирүчедән гафу үтенеп, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен киләчәктә аңа нинди гамәлләр кылырга кирәклеге турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Административ регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатмалар,

шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Медицина эшчәнлеген башкаруга лицензияләр реестрында соратылган мәгълүматларның булмавы турында
БЕЛЕШМӘ

________________________________ медицина эшчәнлеген башкаруга
(дата күрсәтелә)
лицензияләр реестрында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан бирелгән___________________медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия турында мәгълүматлар юк.

_______________________________________________________________________
(медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия турында белешмәләр бирүгә гариза нигезендә юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) күрсәтелә)

_______________________ _______________________
_______________________

| | | |
|---|---|---|
| (министрлыкның вәкаләтле затының вазыйфасы) | (министрлыкның вәкаләтле затының имзасы) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

20__ елның «____» ____________

__________

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Теркәү номеры ______________________________ ________________________
(Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан тутырыла)

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгына

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүгә
гариза*

Юридик затның атамасы (шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)_____________________________________

Юридик зат урнашкан урын адресы (шәхси эшкуар яшәгән урын адресы_____________________________________________________________

ИНН _____________________________________________________

ОГРН ____________________________________________________

Электрон почта адресы ______________________________________

Медицина эшчәнлеген башкаруга ______________________________
(лицензия биргән органның атамасы)
тарафыннан бирелгән ____________________ ___________________номерлы лицензиядә түбәндәге хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

| _____________________________________ | _____________________________________ |
| --- | --- |
| Юридик затның җитәкчесе (шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | (имзасы/көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы) |

20__ елның «____» _____________

___________

* Гаризага хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлары төзәтелергә тиешле документлар теркәлә.

___________